**Промежуточная аттестация**

**Предмет:** дополнительный учебный предмет «Открывая книгу, открываю мир», 11 класс

**Условия проведения процедуры промежуточной аттестации:**

Работа проводится в классе, задания выполняются на заранее распечатанных бланках

**Время выполнения:**

На выполнение всей работы отводится 45 минут.

**Назначение работы:**

Определить уровень овладения предметных результатов, коммуникативных УУД и смыслового чтения у учащихся 11 класса по итогам усвоения программы по дополнительному учебному предмету «Открывая книгу, открываю мир».

**Структура и содержание работы:**

Работа проводится в форме тестирования, состоит из 2х частей:

Часть А. Задания 1-8 с выбором правильного ответа,

Часть Б. Задания на **установление соответствия между текстами А – Е и заголовками 1– 8**.

**Обобщенный план:**

| **№ задания** | **Контролируемые элементы содержания (предметные результаты)** | **Связь с УУД (коммуникативные результаты, смысловое чтение)** | **Тип** | **Балл** |
|---|---|---|---|---|
| **Часть А 1-8** | При чтении текста выделять нужную информацию, систематизировать, сравнивать, анализировать, обобщать, интерпретировать и изменять его содержание. | Умение адекватно использовать речевые средства для решения различных коммуникативных задач; находить в тексте конкретные сведения, факты, заданные в явном виде | Б | 8 баллов |
| **Часть Б** | Владеть навыками чтения научно-популярных, официальных текстов в пределах тем, предусмотренных программой, с полным пониманием их содержания; | Умение адекватно использовать речевые средства для решения различных коммуникативных задач | Б | 7 баллов |
| Всего | | | | 15 баллов |

**Выставление отметки:**

Предметные и метапредметные результаты оцениваются одной единой отметкой

“5” – 15 – 14 б.

“4” – 13 –11 б.

“3” – 10 – 8 б.

“2” – 7 – 0 б

**Демовариант**

**Прочитайте текст. Определите, какие из приведённых утверждений соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2 – текстка туры килми).**

Бик борынгы заманда Керпенең киеме энәле булмаган. Ул көнен дә, төнен дә язын да, көзен дә гап-гади киемнән йөргән. Туңмаган да, аңа эссе дә булмаган. Ләкин бер вакыйгадан соң, Керпе өстендәге киемен үзгәрткән.

Беркөнне ул урманда гөмбә җыеп йөргән. Аңа соры Бүре очраган. Ач Бүре Керпене ашарга теләгән. Керпе тиз генә йомгак булып бөтерелгән дә таудан тәгәрәп төшеп киткән.

Ләкин Бүре дә тиз чаба икән. Аның үткен тырнаклары Керпенең тәпиенә эләккән, аягын авырттырган. Ләкин Керпегә чыршы ылыслары ярдәм иткән. Ничекме? Менә ничек.

Бүредән качканда, Керпе чыршылар яныннан тәгәрәгән. Аның тәненә ылыс энәләре ябышып калган. Бүре кабып йотарга теләгәндә, энәләр аның иренен авырттырганнар. Бүре авыртуга түзә алмаган, Керпене җибәргән. Үзе авызын, борынын тотып, урман эченә кереп киткән.

Керпе бик тапкыр булган. Чыршы энәләренең файдасын шунда ук аңлаган. Аларны җыйган да үзенә күлмәк теккән. Күлмәген бер дә салмаган. Шул көннән башлап, Керпе явыз Бүредән дә, хәйләкәр Төлкедән дә курыкмый башлаган.( Г. Гыйльмановтан)

**А бүлеге**

1. Керпе һәрвакыт энәле күлмәк киеп йөргән.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

2. Керпе беркайчан да туңмаган.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**3.** Керпе урманда җиләк җыйган.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

4.Керпегә төрле җәнлекләр очраган.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

5 . Бүре керпе артыннан чапкан.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

6. Бүре Керпене җәрәхәтләгән.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

7. Чыршы энәләре Керпене коткарганнар.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

8.Керпе хәйләкәр Төлкедән генә курка башлаган.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**Б бүлеге**

**Прочитайте тексты и установите соответствие между текстами А – Е и заголовками 1– 8. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую цифру только один раз. В задании есть один лишний заголовок.**

1. **Урман каравылчысы – кырыс кеше.**
2. **Үтерелгән ябалак.**
3. **Вәлиәхмәт абыйның үкенүе.**
4. **Агачларны сакларга кирәк.**
5. **Ятим калган ябалак.**

6. **Ябалак та – урман сакчысы.**
7. **Каравылчы өенә килү.**
8. **Урманга бару.**

**А**. Көз иде. Яңа гына кар яуган. Без, ат чанасында ятып, урманга барабыз. Җирән кашка ат, тын урманны яңгыратып, пошкырып куя.

**Ә.** Урман каравылчысы Вәлиәхмәт абый - Себер шахталарында йөргән кеше. Ул яшь килеш пенсиягә чыккан да каравылчы булып монда эшли. Урманны саклый. Тик ул - бик кырыс холыклы кеше. Ә урманның җанлы тормышы бар. Бу тормыш ягымлылыкны, игътибарлы булуны ярата.

**Б.** Без Вәлиәхмәт абыйның йорты янына килеп җиттек. Ул безне күрде дә эшен ташлады. Кулындагы сәнәге белән бик каты селтәнеп, тәрәзә башыннан ниндидер җан иясен бәреп төшерде. Мин кар өстендә аксыл кошны күрдем. Куркып киттем.

**В.** Мин:

- Вәлиәхмәт абый, нишләдең син, ябалакны үтергәнсең бит! – дип кычкыруымны сизми дә калдым.

Ул миңа кырыс кына карады да:

- Үлсә ни, тавык урлый бит ул, - диде.

**Г.** Аның җавабын ишетсәм дә, мин дә кырыс итеп әйттем:

– Белмәсәң, бел, Вәлиәхмәт абый, бу кошны чырайсыз ябалак дип атыйлар. Русча сыч була. Синең якын дустың ул. Ул да урманны, йортыңны тычканнардан саклый. Монда да тычкан тавышын ишетеп килгәндер. Ә син аны, Вәлиәхмәт абый, нишләттең?!

**Д.** Соңгы сүземне тавышны күтәреп әйттем. Урман каравылчысы, күзен зур итеп ачып, миңа карады.

- Бу ябалак тавык тотмыймыни? – диде. Ул үкенә, гаҗәпләнә иде. – Карале, үзе матур да, файдалы да икән. Терелтә алмабызмы? – диде. Ләкин мәче башлы ябалакка ярдәм кирәкми иде инде, ул үлгән иде.

**Е**. Ул вакытта мин дә аңламаганмын. Хәзер беләм: ябалакның берсе һәлак булгач, икенчесе ятим кала. Шуңа күрә ятим ябалак язын кычкыра:

– Бу-бу, бу-бу-бу! Син кайда?

Ә без, кешеләр, моны аңламыйбыз. *(М. Рәфыйковтан)*

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** | **Д** | **Е** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | | | |

**Ключи:**

| № | Демовариант |
|---|---|

| | |
|---|---|
| А бүлеге 1 | 2 |
| 2 | 1 |
| 3 | 1 |
| 4 | 2 |
| 5 | 1 |
| 6 | 1 |
| 7 | 1 |
| 8 | 1 |
| Б бүлеге | 8172635 |

2

**1 вариант**

**Прочитайте текст. Определите, какие из приведённых утверждений соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2 – текстка туры килми).**

Һәркемнең үз әнисе үзенә кадерле. Минем әниемнең ягымлы йөзе әле дә күз алдымда. Аның акыллы киңәшләре, җылы сүзләре һәрвакыт исемдә саклана. Ул тормышта күп авырлыклар күргән, ләкин алдагы көнгә ышаныч белән караган.

Башка әниләр кебек безнең әни дә балаларының эшчән булып үсүләрен тели иде. Ул, безне кеше итәр өчен, бөтен көчен бирде. Ә безнең аны борчыган чакларыбыз да булды.

Көзнең матур бер көне иде. Алмалар, көнбагышлар өлгергән вакыт. Әни дә үстерә иде бакча җимешләрен. Бакчабыздагы көнбагышларга һәркем кызыга иде, бигрәк тә малайлар. Көнбагыш ашат әле дип сорыйлар иде. Шулай беркөнне малайлар бик сорагач, әнигә әйтмичә, бакчага кереп киттем һәм көнбагыш башларының иң зурларын өзеп алдым. Аларны малайларга алып чыктым. Шул вакыт колагыма таныш тавыш ишетелде. Артка әйләнеп карасам, әни басып тора. Үзе елмая. Мин ни әйтергә дә белмичә туктап калдым. Әнием мине үз янына чакырып алды да ачуланмый гына өйгә алып керде. Ә өйдә бер төркем кызлар җыелган. «Менә минем улым ничек үсте, үз бакчасы җимешен үзе яшереп ашый» – диде.

Бала вакытта булган бу хәл минем бөтен гомеремә сабак булып калды. Әниемнең «Туры сүзле һәм эштә гадел булырга кирәк» дигән киңәшләрен хәзер дә онытмыйм. Күңелемә әнием салган орлыклар үстеләр, чәчәк аттылар.*(Мөхәммәт Гайнуллиннан)*

**А бүлеге**

1. Һәр кеше өчен әни иң якын кешеләрнең берсе булып тора.

**1) текстка туры килә 2) текстка туры килми**

2. Әнисе әйткән сүзләрне малай хәтерендә калдырган.

**1) текстка туры килә 2) текстка туры килми**

3. Әнисенең тормышы бик җиңел булган.

**1) текстка туры килә 2) текстка туры килми**

4. Әни балаларын тәрбияләүгә зур игътибар биргән, шуңа күрә алар аны борчымаганнар.

**1) текстка туры килә 2) текстка туры килми**

5 Аларның бакчасында көнбагыш бик уңган.

**1) текстка туры килә 2) текстка туры килми**

6 . Малайның дуслары, бакчага кереп, көнбагыш алып чыкканнар.

1) **текстка туры килә 2) текстка туры килми**

7 . Әнисе улын нык ачуланган.

1) **текстка туры килә 2) текстка туры килми**

8 . Бала чагындагы әле вакыйганы бу кеше беркайчан да онытмаган.

1)текстка туры килә 2) текстка туры килми

**Б бүлеге**

**Прочитайте тексты и установите соответствие между текстами А – Е и заголовками 1– 8. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую цифру только один раз. В задании есть один лишний заголовок.**

1. **Бүләкне яшереп кую.**
2. **Абыйсы белән апасының бүләк әзерләүләре.**
3. **Бүләкнең эреп бетүе.**
4. **Илдарның идән сөртүе.**
5. **Су буена баруы.**
6. **Малайның шатлануы.**
7. **Илдарның бүләк турында уйлануы.**
8. **Туганнарның гаҗәпләнүе.**

**А.** Илдар быел Әниләр бәйрәмендә әнисенә башка беркем дә уйлап таба алмаган әйбер бүләк итәргә булды. Ул инде белә: Хәлим абыйсы, әнисенә дип, матур сәгать алып куйды. Нәсимә апасы тәмле исле хушбуй алып кайтты. Илдар аның тәмледән-тәмле исләрен каян беләме? Апасы өйдә юк чакта, ике мәртәбә алып иснәп карады инде ул бу хушбуйны.

**Ә.** Беркөнне тәрәзәдән тышка карап утырганда, Илдарның башына шундый уй килде: әгәр дә ул, кардан әнисенең сынын ясап, 8 Март көнне шуны алып кереп бүләк итсә? Әй сөенер иде әнисе! Илдар шулай итте дә. Әниләр бәйрәменә бер көн кала, ул кич буе кар тәгәрәтте, кар кисәкләреннән бер кеше сыны ясап куйды. Бу сын әнисенә бик тә охшаган кебек тоелды.

**Б.**Шул ук кичтә Илдар үзенең бүләген качырып кына алып кереп, бүлмәсенең бер почмагына бастырып куйды. Җәймә белән капларга да онытмады. Иртән барысы да гадәттәгедән иртәрәк уянды. Ел саен шулай: иртәнге ашка кадәр үк Илдар әтисе, абыйсы һәм апасының котлау сүзләрен, бүләк бирүләрен түземсезлек белән көтте.

**В.** Чират җиткәч, Илдар әнисе янына килде дә: «Хәзер мин үз бүләгемне күрсәтәм», — дип,бүлмәсенә йөгерде. Әмма, бүлмә ишегеннән атлап керүгә, ниндидер суга басуын тоеп алды Илдар. Идәнгә карады да аһ итте: аның «кар әнисе» җылы өйдә эреп беткән, ә кар суы бөтен бүлмәгә җәелгән!

**Г.** Илдар нишләргә дә белмичә каушап калды. Әнисенә нинди бүләк бирә инде ул хәзер? ... Менә сиңа бәйрәм! ... Әнисе күргәнче, тизрәк сөртергә кирәк.Әле ярый бүлмәдә зур агач савытта гөл үсеп утыра. Илдарбөтен суны шул гөл төбенә агыза торды. Инде идәнне сөртеп бетерәм дигәндә генә, зал яктан әнисенең: «Илдар, балам, бүләгеңне карарга чыгыйкмы инде?» — дигән тавышы ишетелде.

**Д.** Илдар соңгы мәртәбә идәнне сыпырып алды да, гөл төбенә соңгы тамчы суны агызып, чүпрәкне карават астына яшереп куйды. Шулвакыт аның янына әнисе, әтисе, абыйсы, апасы килеп керде. Килеп керүгә, юеш идән уртасында басып торган Илдарга карап телсез калдылар...

**Е.** Шул вакыт әнисе:

– И-и-и улым, менә нинди зур бүләк әзерләгәнсең син миңа! Идәнне югансың! Миңа бер эш тә калдырмагансың. Рәхмәт, улым, мең рәхмәт сиңа!.. Кил әле, шуның өчен яратыйм үзеңне! Шулвакыт еларга җыенган Илдарның күзләрендә ниндидер тылсымлы

нур чагылып китте. Һәм ул, дөньядагы иң бәхетле бер малай булып, әнисенең кочагына атылды... *(ГалимҗанГыйльмановтан)*

| Текстлар | А | Ә | Б | В | Г | Д | Е |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Исемнәр | | | | | | | |

**2 вариант**

**Прочитайте текст. Определите, какие из приведённых утверждений соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2 – текстка туры килми).**

Хәят белән Лиза бала вакытларыннан ук бергә уйнап үскән балалар иде... Лиза. Сигез яшеннән быелга кадәр гимназиядә укып, ххәзер урта белемне тәмамлый иде. Хәят, җиде яшеннән ундүрткә кадәр Мәлихә абыстайда укып, үткән кыш аңа йөрүдән туктаган иде.

Хәятнең әтисе Борһан абзый гади бер татар купецы һәм гади татар бае тормышы белән торган кеше иде. Шуңа күрә аның йортындагы һәр кеше, үз теләге һәм үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгылардан килгән кагыйдәләргә буйсынырга һәм шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга тиеш иде. Мясниковлар гаиләсендә һәркемнең үз теләге, үз тойгылары бик күп урында бик күп нәрсәләрдән алда тора иде.

Хәят тормышны икегә аера: мөселман тормышы – монысы үзләренекечә булырга тиешле; рус тормышы – монысы Мясниковларныкыча булырга кирәк дип ышана иде.

**А бүлеге**

1. Кызлар кечкенә чактан ук аралашып үскәннәр.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
2. Лиза белән Хәят бер гимназиядә укыганнар.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
3. Хәят биш ел абыстайда укыган.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
4. Хәятнең әтисе – бай кеше.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
5. Борһан абзый йортындагы кешеләр үз теләкләре буенча яши.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
6. Мясниковлар гаиләсендә хуҗаның сүзе өстен түгел.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
7. Хәят өчен мселман һәм рус тормышы бар.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми
8. Әтисе Хәяткә башка телләрне укытуны кирәк дип тапмый.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**Б бүлеге**

**Прочитайте тексты и установите соответствие между текстами А – Е и заголовками 1– 8. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую цифру только один раз. В задании есть один лишний заголовок.**

1. **Пауза роленең үзенчәлеге.**
2. **Тамшачыларның туктаусыз көлүе.**
3. **Укытучының киңәше.**
4. **Чыгышларның төрле булуы.**
5. **Артистларны кул чабып каршылау.**
6. **Халыкның паузаны көтүе.**
7. **Паузаның сәхнәдә үзен тотуы.**
8. **Артистлар җитмәү.**

**А.** Репетицияләргә керештек. Төп кыенлык шунда чыкты инде, егетләр. Әйткәнемчә, артистлар аз, кайберәүләр икешәр роль уйный. Ә пьесаны әзерли башлагач күрәбез: китап текстында урыны-урыны белән әллә нинди Пауза да очрый бит, әй! Аптыраштa калдык

**Ә**. Безгә шунысы ачык: исеменә караганда, Пауза хатын-кыз булырга тиеш. Рауза шикеллерәк. Берәр апамы ул? Кыз баламы? Нигә теләсә кем арасына килеп керә, ник авыз ачып бер сүз дәшми үзе?

**Б**. Укытучыбыз да төгәл генә әйтә алмады. Аны да гаепләп булмый, бөтен гыйлеме шул газета-журнадан укыганы гына. Шулай да безгә бик яхшы киңәш бирде ул. Пауза ролен мәктәпнең иң үткен малаена тапшырыйк, диде. Кызлар итеп киендерербез, диде.

**В.** Өченче пәрдәнең буеннан буена залда көлеш бер дә тынмады, кайчагында тәрәзә пыялалалры “зың!” итеп куя иде... Без, авылдашлар пьесаны яраттылар, дип сөендек. Тик менә дөнья кубарып көлүнең сәбәбе безнең осталыкта түгел, башкада булган икән.

**Г**. Чибәр Паузабыз сәхнәдә тик тормаган булып чыкты. Сүз дәшәргә роле кушмагач, халык белән аңлашу өчен, Хәниф үз юлын тапкан: башта мулла хатыны булып күрсәткән, икенче юлы кулак Гаптеринең олы кызы аяк өстендә йоклаганны.

**Д.** Соңыннан белемнәребез ныгыгач, Паузаны сәхнәгә чыгармый башлаганнан соң да әле, халык: “Нигә Пауза юк? Паузаны ник катнаштырмыйсыз? Әллә авырыймы?” – дип сорый иде. Шуңа күрә дә Паузаны концертларда катнаштыра идек.

**Е.** Хәнифнең чыгышлары үзенә күрә бер кызык интермедиягә әйләнде. Аның кыланышлары концерттан концертка үзгәреп тора иде. Халык аның чыгышларын гел күтәп алды.

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** | **Д** | **Е** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | | | |

**Ключи:**

| № | Демовариант | 1 вариант | 2 вариант |
|---|---|---|---|
| А бүлеге 1 | 2 | 1 | 1 |
| 2 | 1 | 1 | 2 |
| 3 | 1 | 2 | 2 |
| 4 | 2 | 2 | 1 |
| 5 | 1 | 1 | 2 |
| 6 | 1 | 2 | 1 |
| 7 | 1 | 2 | 2 |
| 8 | 1 | 1 | 2 |
| Б бүлеге | 8172635 | 2713486 | 8132746 |